«Раслыйм»
_______________________
Мәгариф идарәсе башлыгы
Р.Н. Хуҗин

«Килешенгән»
_______________________
МАӨББУ 14 санлы Балалар-яшүсмерләр үзәге директоры
Н.Ә. Рәхмәтуллина

**Татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның «ТАТАР СҮЗЕ» Республика бәйгесе муниципаль этабы конкурсы турында нигезләмә**

**1. Конкурсның максатлары һәм бурычлары**

Татар телен һәм әдәбиятын популярлаштыру, татар нәфис сүзенә кызыксыну уяту, шигъри аһәңне тоярга өйрәнү максатларында 2020 елдан башлап татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның «Татар сүзе» бәйгесе үткәрелеп килә. Бәйгедә һәр елны, республикадан тыш, Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән меңләгән артык кеше катнаша.

Бу чара татар классик әдәбиятын пропагандаларга, татар әдәбиятына карата кызыксыну уятырга, талантлы нәфис сүз осталарын барларга һәм аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итә. Бәйге 2023 ел - Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында үтә.

**2.Конкурсны үткәрү вакыты**

Яр Чаллы шәһәрендә 01.03.2023 – 14.04.2023 вакыт кысаларында үткәреләю.

**3. Конкурста катнашучылар**

Катнашучылар түбәндәге категорияләргә бүленә:

**11 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне дә кертеп) катнашучылар**

**4. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә**

а) поэзия (шигырь, поэмалардан өзекләр);
б) проза;
в) мәсәл.

**5. Конкурс эшләренә таләпләр**

а) конкурс татар телендә үткәрелә;

б) конкурста катнашучылар барлык номинацияләр (поэзия, проза, мәсәл) буенча конкурс эшләре тәкъдим итәргә мөмкин;

в) конкурс эше яттан сөйләнгән яисә укылган монолог яки диалог рәвешендә әдәби әсәрне бәян итүдән гыйбарәт чыгыш булырга тиеш;

г) катнашучының чыгышы музыкаль бизәлеш белән барырга мөмкин;

д) бәян ителә торган әдәби әсәр катнашучының яшенә туры килергә тиеш;

е) чыгыш ясау вакыты 5 (биш) минуттан артмаска тиеш.

**6. Конкурс ике этапта уздырыла**

Конкурс эшләрен сайлап алу шарты катнашучыларның башкару осталыгыннан (актерлык осталыгы, дикция һ.б.), шулай ук чыгышның (шул исәптән костюмның, реквизитның, музыкаль бизәлешнең) оригиналь булуыннан гыйбарәт.

Беренче этап (сайлап алу этабы) барышында Конкурста катнашучылар конкурс эшләрен видеоязма рәвешендә электрон форматта түбәндәге электрон почта адресына җибәрәләр: akhmetova.farida@inbox.ru

Конкурс эшләре беренче этапта 2023 елның 31 мартына кадәр кабул ителә.

01.04.2023-12.04.2023 жюри тапшырылган конкурс эшләрен карый.

Икенче этапта – 13.04.2023 дә конкурста катнашучылар жюри алдында чыгыш ясый.

Конкурста җиңүчеләр диплом белән бүләкләнәләр.

8-917-241-66-76 Әхмәтова Фәридә Гариф кызы